Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы

Тубэн Оскебаш авыл җирлеге башлыгы

# КАРАРЫ

2025 елның 12 ноябре № 2

## Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Тубэн Оскебаш авыл җирлегенең Тубэн Оскебаш авылында гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Тубэн Оскебаш авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.Кукмара муниципаль районы Тубэн Оскебаш авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының 1 нче этабын 2025 елның 28 ноябрендэ 10 сәгать 00 минутта билгеләргә. Тубэн Оскебаш авылы, Советская ур., 66А йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында гражданнар җыенын үткәрергә.

2. 2025 елның 29 ноябрендэ 10 сәгать 00 минутта Кукмара муниципаль районы Тубэн Оскебаш авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын билгеләргә.Тубэн Оскебаш авылы, Советская урамы, 66А нчы йорт адресы буенча урнашкан мэдэният йорты бинасында гражданнар җыены үткәрергә.

3.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар, I төркем инвалидлары, 18 яшькә хэтле 4 һәм аннан артык бала булган күп балалы гаиләләр, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлегенең Түбән Өскебаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, Хәрби хезмәткә мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 2026 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

-су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су коймасын тәэмин итүче башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен җиһазлар тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау;

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү;

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

- гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юлүткәргечләрне, җәяүлеләр җир өсте кичүләрен торак пункт чикләрендә ремонтлау

“ӘЙЕ” « КАРШЫ»

4.Халык җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) хәл итәргә кирәк.

5. Халык җыенын Тубэн Оскебаш авыл җирлеге башкарма комитеты оештыра.

6. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә кабул ителгән көннән 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Тубэн Оскебаш авыл җирлеге башлыгы Н.М.Мохэммэтжанов